РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬШИХОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛШИХ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 ноябрь 2022 ел № 72

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Алших авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Указы нигезендә, Алших авыл җирлеге Уставына таянып, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән Кайрево авылының 2022 елның 8 ноябрендәге 1 номерлы, Нурвахит авылының 2022 елның 9 ноябрендәге 1 номерлы, Теңкәш авылының 2022 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы, Алших авылының 2022 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы карарларын тормышка ашыру максатларында Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Алших авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» 2022 елның 14 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Алших авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 пунктына киләсе редакциядә 2нче абзацны өстәргә:

«Үзара салым акчаларын түләүдән азат итәргә:

- Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар, шулай ук мобилизацияләнүче белән бергә яисә аннан аерым яшәүче гаилә әгъзаларын;

- Украинадагы махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрбиләр, шулай мобилизацияләнүче белән бергә яки аннан аерым яшәгән гаилә әгъзаларын;

- Украинада махсус хәрби операция зонасында булган волонтерлар, шулай ук мобилизацияләнүче белән бергә яки аннан аерым яшәүче гаилә әгъзаларын.»

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Алших авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Алших авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 22 ноябрендә 12 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм ТР, Буа районы, Алших авылы, Правда урамы, 48а адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.П. Андреев